УДК 371

# Буа шәһәрендә ислам дине тарихы

***Р. И. Маликов,***

*Казан федераль университеты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# Islamic history of Buinsk city

***R. I. Malikov,***

*Kazan Federal University, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**

Город Буинск исторически сложился как один из значимых мусульманских религиозных центров Поволжья. До революции здесь проживало более двух тысяч татар-мусульман, действовали две соборные мечети и два крупных медресе, где работали видные религиозные деятели. Татарское население полностью исповедовало ислам. Среди них были богатые купцы, которые финансировали строительство и содержание мечетей и медресе. В советский период все мечети и медресе были закрыты, уничтожена многовековая религиозная литература, репрессированы и изгнаны религиозные деятели, благотворители. Народ воспитывался в духе коммунистических идей, формировался идеал советского гражданина, далекого от религии и религиозных традиций. Несмотря на насильственное навязывание атеистических взглядов, часть татарского населения г. Буинска сумела сохранить верность своим религиозным убеждениям, национальной культуре и традициям. В этом большую роль сыграли неофициальные религиозные деятели: имамы и абыстаи. С распадом в 1991 г. СССР и образованием Российской Федерации, началась новая эпоха постепенного возрождения ислама. В настоящее время в Буинске действуют шесть мечетей и одно медресе. Цель данной работы раскрыть историю ислама в г. Буинске. Данная тема долгое время оставалась неизвестной, поэтому ее изучение актуально для исторического краеведения. Работа выполнена с использованием широкого круга источников (документы Государственного архива Республики Татарстан, Государственного архива Ульяновской области, Национального архива Республики Башкортостан), материалов периодической печати, научной литературы и личного архива автора.

**Abstract**

The city of Buinsk historically emerged as one of the significant Muslim religious centres of the Volga region. Prior to the revolution, more than 2000 Muslim Tatars lived there, two cathedral mosques and two large madrasahs were functioning having prominent religious figures among

their staff. The Tatar population completely professed the Islamic faith, including rich merchants who financed the construction and maintenance of mosques and madrasahs. During the Soviet period all the mosques and madrasahs were closed, centuries-old religious literature was destroyed, religious leaders and benefactors were subjected to repression and purged. People were indoctrinated with red ideas, the ideal of the Soviet citizen far from religion and religious traditions was formed. Despite the violent intrusion of atheistic views, a part of the Tatar population of Buinsk managed to remain faithful to their religious convictions, national culture and traditions connected with Islam. Informal religious leaders like imams and abystays played a significant role in it. With the collapse of the USSR and formation of the Russian Federation a new era of gradual revival of Islam began. At present 6 mosques and 1 madrasah work in Buinsk. However, among 14 470 Tatars living in the city only about 7 % are considered religious practicing. The purpose of this work is to provide insight into the history of Islam in Buinsk. This topic has remained unknown for long, therefore the study of this topic is relevant to historical regional studies. The work is carried out using a wide range of sources (documents of the State Archive of the Republic of Tatarstan, the State Archive of Ulyanovsk region, National Archive of the Republic of Bashkortostan), periodicals, scientific literature and the author's private archive.

**Ключевые слова**
История г. Буинска, мечеть, медресе, имам, абыстай, мусульмане, благотворители, отношение власти к религии.

**Keywords**
History of Buinsk, mosque, madrasah, imam, abystay, Muslims, benefactors, attitude of authorities towards religion.

Буа Татарстанның көньяк-көнбатышында Карлы елгасы буенда (Зөя елгасы кисешендә) Казаннан 137 км, Ульяннан 80 км ераклыкта урнашкан зур булмаган шәһәр. Шәһәрнең исеме «Буа», плотина сүзеннән алынган. Тарихтан мәгълүм булганча Идел буе Болгар дәүләте чорында болгар авыллары Буа җирлегендә дә булган[1], ә соңрак Казан ханлыгы вакытында бу урында зур булмаган шәһәр барлыкка килгән[2].

## Революциягә кадәрге чорда ислам дине

Буа шәһәре гомер-гомергә аеруча дини төбәк буларак башка төбәкләрдән аерылып торган. Бигрәк тә революциягә кадәр бу мәчетләрнең, мәктәп-мәдрәсәләрнең күплегендә, халыкның дини булуында, гыйлемле, көчле дин әһелләренең фидакарь эшчәнлегендә күренгән.

Тарихи мәгълүматларга караганда, Рус дәүләтнең 250 ел барган көчләп чукындыру сәясәте туктатылгач 1788 елны Оренбург өлкәсе мөселманнар Диния нәзарәте төзелә һәм мәчетләр салырга рөхсәт бирелә. Шул вакытларда Буада да, ниһаять, агач мәчет төзелә. 1805 елны аның каршында мәдрәсә ачыла[3]. Ул вакыттагы мәдрәсә җитәкчеләре, имамнары Фазыл бине Нигмәтулла әл-Буави, Хөсәен бин Хөснетдин әл-Буавый, 1836-1852 елларда Габделвахид бине Габдеррахман бине Колый әл-Буавый (1808-1852) була.

1852-1886 елларда Буа мәдрәсәсен Габдуннасыйр хәзрәт Мөхәммәтәминов (1806-1886) җитәкли. Бу кеше галим кешеләрдән булып күп гомерен ислам дине үсешенә, гыйлем бирүгә, күркәм шәкертләр, имамнар тәрбияләүгә сарыф итә. Аның вакытында мәдрәсәнең даны еракларга тарала. Ул мәшһүр галим Шиһабетдин

Мәрҗани белән дус булып, кызы Зөһрәне аңа кияүгә бирә. Замандашлары аның хакында ошбу сүзләрне язып калдырганнар: «Габденнасыр хәзрәт фәкыйрьлек белән Исәк, Бәрәскә, Бохара мәдрәсәләрендә укып, тырышлык сәбәпле зур гыйлемнәр алды. Һәрвакыт гади тормыш алып барды кайбер галимнәр, шәйхләр кебек байлык җыймады. Бу дөнья малына бәйле түгел иде. Күпме акча килсә, шуны куллана, булганына канәгать булып яши иде. Вафат булганда бар акчасы 100 сумнан артык булмады. Суфый һәм захид иде. Күркәм холыклы булып телен гөнаһлардан мөмкин кадәр саклый иде, теле белән, язуы белән бер кешенең хәтерен калдырмады. Бөтен вакытын шәкертләргә гыйлем бирүгә һәм күркәм әхлаклы шәхесләр тәрбияләүгә сарыф итте»[4].

1882 елның 20 августында Буада, көчле янгын чыгып, татар бистәсе, шул исәптән мәчет һәм Буа мәдрәсәсе бинаклары тулысынча янып бетә[5]. 1883 елның язында Буада ике кибет тотучы икенче гильдия сәүдәгәре Шәрип Гобәйдулла улы Муллинның акчасына 200 кеше сыйдырышлы, кирпеч белән тышланган матур агач мәчет салына[6]. Шунда ук мәдрәсәнең кирпеч һәм агач биналарын салу алып барыла[7]. Бу кеше алга таба мәдрәсәнең эшчәнлегенә, Буа өязендә мәчетләр салуда үзенең күп малларын сарыф итә.

Буа мәдрәсәсенең чәчәк ату еллары XIX гасыр ахырына – XX гасыр башына туры килә. Ул вакытта аның җитәкчесе, мөдәррисе булып ахун, ишан Нургали Хәсән әл-Буавый тора. Ул 1852 елның ноябрендә Татарстанның бүгенге Апас районындагы Морзалар авылында мулла гаиләсендә туа. Кечкенәдән Казанда Исхаковлар мәдрәсәсендә укый[8]. Соңрак Бохара шәһәрендә «Мир – Араб» югары мөселман дини мәдрәсәсен тәмамлый һәм зур гыйльми дәрәҗәләргә ирешә[9]. 1886 елның 12 декабрендә ул Буа мәчете һәм мәдрәсәсенә имам-хатыйб, мөдәррис итеп сайлана[10]. Аның үзе язып калдырган җиде китабы бүгенге көнгә кадәр сакланган.




*Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 88 ф., 2 тасв., 1904 эш, 5 кгз.*

*The State Archive of Ulyanovsk region, fond 88, series 2, file 1904, p. 5.*

Үз эшчәнлеге елларында Нургали хәзрәт җитди дини уку йорты оештыруга ирешә. Мәдрәсә өч бүлектән торган: башлангыч (ибтидаия), урта (рөшди) һәм югары (игъдадия). Анда Буа өязенең булачак дин әһелләренең 60-70 % гына түгел, илнең ерак өлкәләре, хәтта Әстерхан губерниясеннән шәкертләр килеп тирән дини белем ала[11]. Укучыларның болай агылышы киңәйтелгән укыту программалары һәм мәдрәсәнең электән килгән даны белән аңлатыла[12]. 1913 елны гына биредә 12 укытучы ярдәмендә 300дән артык шәкерт укый[13]. Бу максатта мәдрәсәдә бай китапханә дә була.

Нургали хәзрәт җирле татар халкының аң-белемле, дини, әхлаклы булуы өчен киңкырлы эшчәнлек алып бара. 1906 елда хаҗ сәфәрендә булып Стамбулда солтан Габделхәмид II белән күрешә һәм беренче дәрәҗәдәге «Османлы» медале белән бүләкләнә. Шулай ук император Николай IIнең «Тырышлыгы өчен» дигән алтын һәм көмеш медальләр белән бүләкләнә[14].

Нургали хәзрәт вакытында Буа мәдрәсәсендә татар халкының күп кенә танылган дин әһелләре, мәдәният, мәгариф һәм фән эшлеклеләре укый. Болар арасында Һади Атласи, Зариф Бәшири, Гомәр Толымбай, Бакый Халидов, Габдрахман Таһирҗанов, Ибраһим һәм Касыйм Биккуловлар, Шиһабетдин Әхмәрев, Ярулла Вәлиев, Кәрим Сәгидев, Гарифҗан Вәлиди, Шакир Мөхәммәдиев, Фатыйх Мортазин, Камаретдин Салихов һ. б. Шуңа да ул заманында иң танылган мәдрәсәләрдән була[15]. Шунысы кызыклы, ул вакытта мәдрәсәдә ислам динен кабул иткән чувашларның балалары да укый[16].



*Габдуннасыйр хәзрәт Мөхәммәтәминовның кабер ташы. Буа шәһ., 2016 ел.*

*The tomb of Gabdunnasyr khazrat Mukhammataminov. Buinsk, 2016.*

Буа мәдрәсәсе укучыларның әти-әниләре, мәхәллә халкы шәхси хәйриясе һәм вакф маллары ярдәме хисабына тотылган[17]. 1910 елның 15 декабрендә оешкан «Буа өязе мөселманнары хәйрия җәмгыяте» дә уку йортының күп кенә чыгымнарын каплауда ярдәм итә. Бу хәйрия оешмасы шулай ук өяздә яңа мәчет-мәдрәсәләр төзелешендә, аларны тәэмин итүдә, ятим, ярлы, мохтаҗларга, авыруларга, тол калганнарга булышуда, бурычка акча биреп торуда, мөселманнар арасында берәрсе сәүдә эшен башлаганда, янып йортсыз калганнарга, мохтаҗ шәкертләргә, гомумән, өяз мөселманнарына бөтен яклап ярдәм итүгә юнәлтелгән була. Оешмага акчалар өяз татар байларының еллык зәкәт сәдакаларыннан һәм оешма әгъзаларының әгъзалык өчен түләүләрдән (членский взнос) җыелган. Акчалар, Буа шәһәр банкында сакланып,

махсус сайланган комиссия тарафыннан хәл ителеп, кирәкле урыннарга бирелгән[18].

Буада көчләп чукындыру сәясәтенең нәтиҗәсе буларак 30лап керәшен гаиләсе яши[19]. Алар шәһәрнең Троицкий чиркәвенә беркетелгән була. Формаль рәвештә христиан динендә булсалар да, чынлыкта ислам дине кануннары белән яшиләр. Ирләре мәчеткә йөри, ир балалары мәдрәсәдә укый, кызлары абыстайдан белем ала. Баштарак аларның хокукый, формаль яктан да ислам диненә күчәргә рөхсәт сораган мөрәҗәгатьләре Сембер рухи консисториясе тарафыннан кире кагылса да, 1905 елгы Беренче революция аркасында, Русиядә вөҗдан һәм дин иреге турында закон кабул ителүе нәтиҗәсендә, алар барсы да хокукый яктан мөселман дип атала башлыйлар. Өяздәге күп татар авылларында да шундый ук хәл кабатлана.



*Нургали хәзрәт Хәсәнов. Якынча 1907нче еллар.*

*Nurgali khazrat Khasanov. Round 1907.*

Буада мөселманнарның артуы сәбәпле, 1905 елны халык һәм җирле татар байлары акчасына икенче мәчет ачыла. Аның имамы итеп Габдулла хәзрәт Гобәйдуллин сайлана[20]. Ул Карлы авылының имамы Гобәйдулла ишан Рәхмәтуллинның улы була[21]. Казанда галим Шиһабетдин Мәрҗанидә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып зур гыйлемнәр алган кеше.

1907 елны мәчет каршында махсус бина салынып «Хыйльмия» исемле җәдиди башлангыч мәдрәсә ачыла[22]. Анда җиде укытучы (хәлфә) мәхәлләдәге һәм якынтирә авылларның ир балаларына дини һәм дөньяви белем биргәннәр[23]. 1913 елны биредә 150ләп шәкерт төрле сыйныфларга бүленеп укыган[24]. Габдулла хәзрәт аң белем таралуына, ислам дине үсешенә зур тырышлык куйган. Хатыны Шәмсия абыстай Гобәйдуллина кыз балаларны укыткан.

Буа шәһәре элек-электән суфыйчылык үзәкләреннән саналган. XX гасыр башында Нургали хәзрәт һәм Габдулла хәзрәт зур ишаннар булып күп кенә мөридләр, күркәм шәхесләр тәрбияләгән. Аларның тырышлыгы белән шәһәрдә, якын-тирәдә яшәүче халык бик дини булган.

1919 елның 19 маенда Беренче мәчет имамы Буа мәдрәсәсе җитәкчесе Нургали хәзрәт Хәсәнов вафат була. Аның эшен уллары Гаязетдин хәзрәт (1889-1937) һәм Ибраһим хәзрәт Хәсәновлар (1895-1937) алып бара.

### Совет чорында ислам дине

1918 елны хакимиятне большевиклар алгач, илдәге диннәргә карата сәясәт үзгәрә башлый. 1918 елның 23 гыйнварында СНК РСФСР «Об отделении церкви от государства и школы от церкви» дигән декреты белән дәүләтнең дингә кагылмавы



*Буа шәһәренең Икенче җәмигъ мәчете. 1988 ел.*

*The second cathedral mosque of Buinsk. 1988.*

вәгъдә ителсә дә, 1919 елны шәһәрдәге Икенче мәчет каршындагы мәдрәсә совет мөселман мәктәбенә әйләндерелә, 1926 елларда бөтенләй дин укыту бетерелә. Алар гади совет мәктәбенә үзгәртелә.

Буада 1921-1923 еллардагы коточкыч ачлык күп кешенең гомерен өзә. 1923 елның 13 октябрендә Икенче мәхәллә мәчетенең имамы Габдулла хәзрәт Гобәйдуллин тиф авыруыннан вафат була[25]. Аның урынында имам булып 1923-1930нчы елларда Вафа хәзрәт Хәмидуллин, 1930-1939 елларда Мөхәммәтҗан хәзрәт Гафаров хезмәт итәләр[26].

1927 елны Буа өязе ахуны, мөхтәсибе[27] Габдесамат Шаһидуллин яңадан мәдрәсә ачу буенча йөри. Әмма Буа кантон идарәсенә рөхсәт бирүне сорап күп тапкыр мөрәҗәгать итүләре нәтиҗәсез кала[28]. Алга таба дингә каршы көчле пропаганда башлана. 1927 елның гыйнварында Буа шәһәрендә дә Алласызлар союзының оешмасы ачыла (1930 елларда Сугышчан алласызлар союзына үзгәртелә)[29]. Ул дингә каршы көрәшүче, атеизм таратучы көчле дәүләт оешмасы була. Аның республикадагы һәр авылда диярлек клуб, мәктәп каршында үз ячейкалары була. Ул үз эшенә күбесенчә яшьләрне җәлеп итә. Оешма тарафыннан дингә каршы китап, гәзит-журналлар таратыла, махсус спектакльләр куела, мәктәпләрдә фәнни-атеистик түгәрәкләр



*Буа мәдрәсәсе биналары. 1997 ел.*

*A madrasah building in Buinsk. 1997.*



*«Госман» мәчете. Буа шәһ., 2015 ел.*

*Gosman mosque. Buinsk, 2015.*

оештырыла, төрле җирләрдә «Алла бармы?», «Ислам һәм коммунизм», «Ислам һәм хатын-кыз», «Фәнни үсеш һәм дин» кебек темаларга доклад, лекцияләр укыла, мәдәният кичәләре үткәрелә һ. б.

1930 елның 1 гыйнварында, мөселманнарның каршылыгына карамастан, Беренче мәхәллә мәчете «законлы нигездә» ябыла[30]. Мәчет манарасы киселү белән, гади совет мәктәбенә әйләндерелә[31]. Мөселманнарның җирле дәүләт оешмаларына күп мәртәбә мөрәҗәгать итүләре файдасыз була[32]. Шул елларны мәчетнең соңгы имамы Ибраһим хәзрәт Хәсәновның йорт-җире тартып алына. Ул зур гаиләсе белән кешедән кешегә күчеп йөри. Ахырдан бер йортның подвалында торалар. Ачы хәсрәттән 1937 елны йөрәге тотып вафат була. Ә Икенче мәхәллә мәчете 1939 елны манарасы киселеп ябыла[33]. Ул М. Вахитов мәктәбе тулай торагы буларак файдаланыла, анда өлкән сыйныфларда укучы авыл балалары яши.

Шулай итеп, Совет хөкүмәте 1920-1930 еллар дәвамында сәяси, икътисади, хокукый, административ юллар белән дин әһелләрен юкка чыгаруга һәм мәчет, мәдрәсәләрне ябуга ирешә. Моның нәтиҗәсендә илдә ислам диненең үсешенә бик зур зыян китерелә, халыкның дини традицияләре өзелә[34].

Мөселманнар дини гыйбадәтләрне үтәү өчен яшерен рәвештә билгеле бер өйләрдә, гает намазына татар зиратында җыелырга мәҗбүр булалар. 80нче елларда Буаның төрле өлешләрендә мөселман җәмәгатен берләштергән шундый биш вакыт намаз уку йортлары гамәлдә була (К. Маркс ур., 91, Колхоз ур., 51, К. Либкнехт ур., 66, Маяковский ур., 36 һ. б.). Әлбәттә, әлеге җәмәгатьләргә өлкән буын вәкилләре генә йөри (яшь һәм урта буынның йөрмәве илдәге коммунистлар партиясе алып барган сәясәткә бәйле). Һәр җәмәгатьнең үз дини җитәкчеләре, имамнары була. Болар: Мөхәммәтҗан хәзрәт Гафаров (1886-1944), Габделкадыр хәзрәт Ногманов (1880-1952), Захидә абыстай Идиятуллина (1874-1945), Фәизә абыстай Халикова (1906-1980), Шәрифҗан хәзрәт Низаметдинов (1878-1952), Исмагыйль хәзрәт Идрисов, Шакирҗан хәзрәт Бикмөхәммәтов (1879-1971), Гыйлмикамал абыстай Бикмөхәммәтова (1897-1985), Камил хәзрәт Бикмөхәммәтов (1922-2000), Ибраһим хәзрәт Хәмидуллин (1912-1984), Гарифҗан хәзрәт Гыймалтдинов (1910-1998),

Җамалетдин хәзрәт Фәизов (1887-1975), Фатыйх хәзрәт Фәтхуллов (1903-1989), Фәизә абыстай Ногманова (1900-1987), Бибирәхимә (Рәхимә) абыстай Җаббарова (1908-2007), Расых хәзрәт Сөнгатуллин (1903-1995) һәм башкалар[35]. Алар барысы да, куркыныч булуга карамастан, халкыбызның динен саклауга зур тырышлык куялар. Халыкның мөһим традицион дини йолаларын үтиләр (исем кушу, никах, күмү, өчләрен, җиделәрен үткәрү һ. б.).

1987 елны Икенче мәчетне мөселманнарга кайтару өчен Мөлеков Малик Гариф улы фикердәшләре белән йөри башлый. Күп юлларны үтеп, зур авырлыклар күреп СССРның Министрлар советы каршындагы дин эшләре буенча советыннан мәчетне кайтаруга ирешәләр. Кыска вакытта реконструкция ясалып – 1988 елның 8 ноябрендә тантаналы рәвештә ачыла һәм тулы көченә эшли башлый. 1989 елның җәендә Буа шәһәренә мөфти Тәлгать Таҗетдин килеп рәсми имамнарын билгели. Бүгенге көндә ул мәчет «Габделмалик» исемен йөртә.

Совет хөкүмәте елларында дингә, милли мәдәнияткә бик зур зыян салына. Өч буын диннән ерак үсә. Моның нәтиҗәсендә җәмгыятьне упкынга илтүче күпсанлы җитди әхлакый-социаль проблемалар барлыкка килә.

### Бүгенге көндә Буада ислам дине

1991 елны Совет хөкүмәте таркалып Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы барлыкка килгәч Буада ислам диненең яңадан әкренләп күтәрелү чоры башлана. 1994 елны Имам һәм Равия Салаховлар оештыруы белән «Госман» исемендәге Икенче җәмигъ мәчете ачыла, 1995 елны «Тәкъва»мәчете төзелә. 1996 елны Малик Мөлеков тырышлыгы белән Буа мәдрәсәсе биналары кайтарылып яңадан эшли башлый. 2003 елны «Әниләр» мәчете, 2008 елны «Хаҗилар» мәчете, 2015 елны «Камилә» мәчете ачыла. Аларның һәрберсендә дини белемле имамнар бар.

2017 елгы статистика буенча Буа шәһәрендә 20 905 мең кеше яши. Шуларның 14 470 меңе татарлар[36]. Якынча 7 % ислам динен гамәлдә тотып яши. Билгеле ислам дине үсеше өчен көчле кадрлар, матди чыганак, нәтиҗәле зур хезмәт һәм вакыт кирәк. Боларның барсыда булдырылса, Буа шәһәре элеккеге вакыттагы кебек татар халкының көчле дини, милли үзәкләренең берсе булыр дип өметләнеп калабыз.

### ИСКӘРМӘЛӘР:


1. Буа ягым – тау ягым. – Казан, 2000. – Б. 34.
2. Русский энциклопедический словарь / Гл. ред. И. Н. Березин. – СПб.: Тип. т-ва «Общественная польза», 1873-1879. – Т. 4. – С. 404.
3. Ульян өлкәсенең дәүләт архивы, 99 ф., 1 тасв., 1275 эш, 67 кгз. арткы ягы.
4. Шунда ук. – Б. 138.
5. Татарстан Республикасы дәүләт архивы, 542 ф., 1 тасв., 12 эш, 10 кгз.; Байрак. – 2008. – № 65.
6. Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 88 ф., 1 тасв., 123 эш, 53 кгз.; Байрак. – 2008. – № 65.
7. *Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р.* Мусульманская община г. Буинска и Буинского уезда на рубеже XIX – начала XX в. // Мечети в духовной культуре татарского народа (XVII в. – 1917 г.). Материалы Всероссийской научно-практической конференции (25 апреля 2006 г., г. Казань). – Казань, 2006. – С. 240.
8. Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 76 ф., 7 тасв., 99 эш, 86 кгз. арткы ягы.
9. Шунда ук, 99 ф., 1 тасв., 1182 эш, 42 кгз.
10. Шунда ук, 76 ф., 7 тасв., 909 эш, 121 кгз.
11. Шунда ук, 99 ф., 1 тасв., 1182 эш, 42 кгз.

12. Шунда ук.
13. Буа мәдрәсәләре // Мәктәп. – Казан, 1913. – № 5; Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 99 ф., 1 тасв., 1182 эш, 42 кгз.
14. *Нургали бин шейх Хасан ал-Казани.* Ал-гауатыф ал-хамидия фиссаяхати нурия. – Казань: Братья Каримовы. – 1907. – С. 21-26; *Нургали бин Хасан аль Казани, аль Мирзави.* Жаулан. – Оренбург: Дин ва магыйшат. – 1910. – С. 25.
15. *Маликов Р. И.* История Буинского медресе. – Казань: Изд-во Казан. университета, 2015. – С. 4.
16. Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 88 ф., 1 тасв., 1930 эш, 109 кгз.
17. Шунда ук, 99 ф., 1 тасв., 1182 эш, 42 кгз.
18. Буа уезды мөселманнары «җәмгыять хәйрия»сенең низамнамәсе. – Казан, 1910; Буа өязе мөселманнары «җәмгыять хәйрия»сенең отчеты. 1910-1911нче ел өчен. – Казан, 1912.
19. Ульян өлкәсе дәүләт архивы, 134 ф., 7 тасв., 807 эш, 76 кгз.; 619 эш, 181 кгз.
20. Шунда ук, 88 ф., 4 тасв., 227 эш, 57 кгз.
21. Шунда ук, 99 ф., 4 тасв., 209 эш, 84 кгз; Буа ягым – тау ягым. – Казан, 2000. – Б. 14.
22. Татарстан Республикасы дәүләт архивы, Р-3682 ф., 3 л тасв., 449 эш, 23 кгз.; Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр җыелмасы. – Т. I: Административ районнар. – Казан, 2002. – Б. 168.
23. *Салихов Р., Хәйретдинов Р.* Татарстан җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры – XX башы). – Казан, 1995. – Б. 200.
24. Буа мәдрәсәләре // Мәктәп. – Казан. – 1913. – № 5.
25. Башкортстан Республикасы милли архивы, И-295 ф., 2 тасв., 1 эш, 26 кгз.
26. Татарстан Республикасы дәүләт архивы, Р-2482 ф., 1 тасв., 104 эш, 182 кгз.
27. Мөхтәсиб – мөселманнарның дини мәсьәләләре буенча җитәкчесе.
28. Татарстан Республикасы дәүләт архивы, Р-2482 ф., 1 тасв, 104 эш, 44 кгз.; *Миннуллин И. Р.* Мусульманское духовенство и власть в Татарстане (1920-1930 гг.). – Казань, 2006. – С. 191.
29. Татарстан Республикасы дәүләт архивы, Р-5263 ф., 1 кгз., 16 эш, 8 кгз.
30. Шунда ук, Р-732 ф., 6 тасв., 31 эш, 150 кгз.
31. Шунда ук, Р-873, 2 тасв., 14 эш, 25 кгз. арткы ягы.
32. Шунда ук, Р-143, 1 тасв., 633 эш, 61 кгз.
33. Шунда ук, Р-873, 2 тасв., 14 эш, 25 кгз.
34. *Миннуллин И. Р.* Мусульманское духовенство и власть в Татарстане (1920-1930 гг.). – Казань, 2006. – С. 165.
35. *Маликов Р. И.* Буа шәһәренең мөселман гыйбадәтханәләре тарихы. – Казан: «Идел-Пресс», 2009 – С. 24.
36. Численность населения Российской Федерации по муниципальным образованиям на 1 января 2017 г. Электрорнный ресурс. Режим доступа: https://ru.wikipedia.org/wiki/Буинск (Татарстан).


**Әдәбият исемлеге**


Буа ягым – тау ягым. – Казан: Идел-пресс, 2000 – Б. 34.

*Миннуллин И. Р.* Мусульманское духовенство и власть в Татарстане (1920-1930 гг.). – Казань, 2006. – С. 165.

*Салихов Р., Хәйретдинов Р.* Татарстан җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры – XX башы). – Казан, 1995. – Б. 200.

**References**

Bua yagym – tau yagym [Buinsk, my wide spread of country]. Kazan, Idel-press publ., 2000, p. 34.

Minnullin I. R. *Musulmanskoe duhovenstvo i vlast v Tatarstane (1920-1930 gg.)* [Muslim clergy and the authorities in Tatarstan (1920-1930ss)]. Kazan, 2006, p. 191.

Salikhov R., Khayrutdinov R. *Tatarstan zhomhuriyate: Tatar halkynyn tarihi hem medeni heikellere (XVIII gasyr ahyry – XX bashy)* [The Republic of Tatarstan: historical and cultural monuments of Tatars (late 18th – early 20th century.)]. Kazan, 1995, p. 200.


Фотолар, күрсәтелгәннән кала, авторның шәхси архивыннан.
Photos from the author's privatel archive.


**Сведения об авторе**

***Маликов Рашид Ильязович***, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института международных отношений Казанского федерального университета, e-mail: rashidbua@mail.ru.

**About the author**

***Rashid I. Malikov***, Candidate of Historical Sciences, Senior Researcher at Institute of International Relations, Kazan Federal University, e-mail: rashidbua@mail.ru.



**В редакцию статья поступила 09.01.2019, опубликована:**

*Маликов Р. И.* Буа шәһәрендә ислам дине тарихы // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2019. – № 3. – С. 183-192.

**Submitted on 09.01.2019, published:**

Malikov R. I. *Bua sheherende Islam dine tarihy* [Islamic history of Buinsk city]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov,* 2019, no. 3, pp. 183-192.